Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Күн авылының Алмаз, Чияле, Ильдар Мархабин, Кедр, Кленовая, Клубничная, Малиновая, Рафаэль Сафиуллин, Якты, Кояшлы, Наратлы, Бәхетле, 3 нче Төзүчеләр урамнарында яшәүче гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

19 октябрь, 2024 ел № 7

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Күн авылының Алмаз, Чияле, Ильдар Мархабин, Кедр, Кленовая, Клубничная, Малиновая, Рафаэль Сафиуллин, Якты, Кояшлы, Наратлы, Бәхетле, 3 нче Төзүчеләр урамы гражданнары җыенының 2024 елның 19 октябрендәге беркетмәсе нигезендә карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1. статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Кощаково авыл җирлеге, Иске Кощаково авылы составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәнең 5 өлешендәге 5 пункты нигезендә түбәндәге мәсьәләләр буенча гражданнар җыены: ««Сез, 2025 елда Күн авылының Алмаз, Чияле, Ильдар Мархабин, Кедр, Кленовая, Клубничная, Малиновая, Рафаэль Сафиуллин, Якты, Кояшлы, Наратлы, Бәхетле, 3 нче Төзүчеләр урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын, 90 яшьтән өлкәнрәк кешеләрне, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүп-чарларны бетерү.» **узмаган дип санарга кирәк**.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Күн авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Күн авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Баһауов